Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы Советы

КАРАР

5 февраль 2021 ел № 43

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2019 елның 10 октябрендәге 243 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Коррупциоген факторларны булдырмау максатыннан, Нурлат муниципаль районы Советы, КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 10.10.2019 ел, № 243 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы документлар Нурлат муниципаль районы Башлыгы исеменә рәсмиләштерелә, үтенечнамәдә һәм вазыйфаи затларны һәм оешмаларны Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы тәкъдимнән тора, оешма җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм мөһер белән таныклана (1 нче кушымта)».

1.2. Нигезләмәнең 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Бүләкләү турындагы карар Нурлат муниципаль районы Башлыгының Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарыла торган карары белән биш эш көне эчендә рәсмиләштерелә».

1.3. Нигезләмәнең 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Бүләкләүләр буенча район комиссиясе тәкъдиме нигезендә бүләкләнүченең Нурлат муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасын кире алу (дөрес түгел, нигезләнмәгән дип яисә мотивацияләнгән башка сәбәпләр буенча) тиешле нигезләүдән соң башкарыла. Кире алу турындагы карар Нурлат муниципаль районы Башлыгы тарафыннан кабул ителә».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының социаль өлкә, мәдәният, мәгариф, тәрбия, спорт һәм яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә..

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин